**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2024 елның 20 мае | № 295

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт шартлары турында» 2019 елның 22 апрелендәге 345 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, үзәкләштерелгән бухгалтерияләр, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына караган вазыйфалардан тыш) җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының “Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт шартлары турында” 2019 елның 22 апрелендәге 345 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифасы | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 31 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 29 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 29 500 |
| Бүлек башлыгы | 25 700 | 25 700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер, әйдәп баручы икътисадчы | 23 300 | 23 300 |
| Бухгалтер, икътисадчы | 22 000 | 22 000 |

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.»

1.2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге үлчәмнәрдә билгеләнә:

| Вазифасы | Түбәндәге халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 23 700 | 25 000 |
| Бухгалтер, икътисадчы | 21 400 | 22 500 |

».

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыкларына шундый ук карарны кабул итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (икътисадый үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин